**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 8 сентябрендәге 3125 номерлы карары**

## Казан шәһәре Башкарма комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 18 сентябрендәге 2113-р номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган типлаштырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлегендә Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 4 декабрендәге 4279 номерлы карарында күрсәтелгән муниципаль хезмәт булмау сәбәпле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 13 апрелендәге 242 номерлы «Дәүләт биреме (заказы) урнаштырылган дәүләт хезмәтләрен, Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә күчү чаралары планын раслау турында»гы карарын исәпкә алып **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 4 декабрендәге 4279 номерлы «Җир кишәрлеге ясау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы, 2021 елның 19 маендагы 1237 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 4 декабрендәге 4279 номерлы “Җир кишәрлеге ясау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы, 2022 елның 29 мартындагы 886 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 4 декабрендәге 4279 номерлы “Җир кишәрлеге ясау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ

регламентын раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карарларын гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**